ГЛАВА ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Декабристов, д.35 а, с. Печищи,
422592

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы,
422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Яңа Болгар авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

№ 3, 2020 елның 14 ноябре

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нчы статьясы нигезендә 2020нче елның 14нче ноябрендә узган Яңа Болгар авылында «2021нче елда Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Яңа Болгар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча: - Яңа Болгар авылында су белән тәэмин итүне ремонтлау һәм төзү (полиэтилен торбалар, бетон боҗралар, траншея казу), дигән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә сез риза булырсызмы, дигән мәсьәлә буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 51 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында 42 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 42 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегенең Яңа Болгар авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танылды.
2. «2021 нче елда Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Яңа Болгар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән билгеләнгән ташламалы категория гражданнардан тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган

акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча: - Яңа Болгар авылында су белән тәэмин итүне ремонтлау һәм төзү (полиэтилен торбалар, бетон боҗралар, траншея казу), дигән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә сез риза булырсызмы, дигән мәсьәлә буенча гражданнар җыены карарын таныргa.

3. Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегенең Яңа Болгар авылында гражданнар җыены нәтиҗәләрен Октябрьский авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге башлыгына адресларга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Ш. Р. Азизов